| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» августа 2023 года № 5

**Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 13.12.2022 елгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Росреестрның 10.11.2020 № п/0412 «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» боерыгы белән, Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгының 20.07.2023 ел, № 5 « Алексеевск штбдә 16:05:010503:743, 16:05:010503:739 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында» карары нигезендә,

**карар бирәм**:

1. Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә – «автотранспортны саклау» җир кишәрлекләрен файдалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторы буенча код № 2.7.1 - кадастр номеры 16:05:010503:743 булган җир кишәрлегенә карата түбәндәге адрес буенча урнашкан: штб Алексеевск, Октябрь урамы, 2а йорт, 20 корпус, кадастр номеры 16:05:010503:739 булган җир участогы: штб Алексеевск, Октябрь урамы, 2а йорт, 6 корпус.

2. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына җибәрергә тәкъдим итәргә (Җир-кадастр документациясенә тиешле үзгәрешләр кертү өчен).

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И. К. Свистунов**